ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ _______________ КАРАР _______________

с. Верхний Услон

Югары Ослан муниципаль районы буенча 2023 елның IV кварталына бер квадрат метр торакның уртача бәясен раслау турында

«2023 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 29.08.2023 елның 619/пр номерлы боерыгына һәм «Бәяләүчеләр союзы» КП Эксперт-консультация Советының 2023 (2 яртыеллык) мәгълүматларына ярашлы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның IV кварталына Югары Ослан муниципаль районы территориясендә 2020-2025 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча чаралар үткәрүгә социаль түләүләр күләме исәбеннән, федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына, торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясен авыл җирлегендә яшәүче яшь гаиләләр һәм яшь белгечләргә 60 854 сум 00 тиен күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, ТКХ, элемтә һәм энергетика буенча беренче урынбасары М. М. Черменскийга йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. А. Файрушин

Әзерләде һәм бастырды:
Бурдина Т. Н.

3 нөсхәдә